**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д.22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_11_» ___05_____ 2023 ел** **№ __112__**

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кешеләр күпләп җыела торган урыннарның исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 11 октябрендәге 254 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (22.02.2018 №47, 18.05.2018 №104, 22.04.2019 №95, 11.02.2022 № 34, 15.03.2022 №73 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр һәм объектлар (территорияләр) күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы якланыуына таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияларның) иминлек паспортлары рәвешләрен раслау турында» карарын үтәү йөзеннән карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кешеләр күпләп җыела торган урыннарның исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 11 октябрендәге 254 номерлы (22.02.2018 №47, 18.05.2018 №104, 22.04.2019 №95, 11.02.2022 № 34, 15.03.2022 №73 карарлар редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кешеләр күпләп җыела торган урыннарның исемлеген» 1 нче кушымтаны яңа редакциядә, әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча: http//pravo. tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «______» _____________________ №_________ карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кешеләр күпләп җыела торган урыннарның исемлеге**

| № | Учреждениенең тулы исеме | Объектның факттагы адресы |
|---|---|---|
| **Парклар һәм мәйданнар** | | |
| 1 | Р.К.Ишкәев исемендәге мәдәният һәм ял паркы | Татарстан Республикасы, Азнакай ш., Пушкин ур., 2 |
| **Җәмәгатьчелек фикерен ачык белдерү өчен махсус билгеләнгән территорияләр** | | |
| 2 | Р.К.Ишкәев исемендәге шәһәр мәдәният һәм ял паркы стадионы территориясе | Татарстан Республикасы, Азнакай ш., Пушкин ур., 2 |
| **Офис биналар** | | |
| 3 | Яшьләр үзәге «Яшьләр үзәге» МБУ | Татарстан Республикасы, Азнакай ш., Мәрҗани ур., 22А |